**Кыяклылар семьялыгы** ( VII сыйныфта биология дәресе )

**Фидус Гыйльфанов**.Актаныш районы Яңа Әлем төп гомуми белем бирү мәктәбенең югары квалификация категорияле биология укытучысы.

**Максат:**

*белем бирү:* укучыларга бер өлешлеләр классының кыяклылар семьялыгындагы үсемлекләрнең үзенчәлекле билгеләре турында төшенчә бирү; кыяклылар семьялыгының төп вәкилләрен белү; бу семьялыкка кергән үсемлекләрнең табигатьтә һәм кеше тормышында әһәмиятен өйрәнү.

*фикерләүне үстерү:* гербарийлар белән эшли белү, проблемалы сораулар кую һәм аларны чишәргә өйрәтү, үсемлекләрне чагыштыру, үзенчәлекле билгеләрне табу, нәтиҗә ясау.

*тәрбияви:* коммуникатив эш күнекмәләре булдыру, мәгълүматны тулы һәм төгәл кабул итәргә һәм тапшырырга өйрәтү, үсемлекләргә сакчыл караш һәм икмәккә хөрмәт тәрбияләү.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр формалаштыру.

**Дәреснең методлары:**

1.Сүзле: әңгәмә, аңлату, сөйләм.

2.Күрсәтмәле: ТСО, гербарий үрнәкләре, таблицалар, тестлар,коллекция.

3.Практик: Лаборатор эш: “Кыяклыларның гомуми билгеләре”.

**Дәреснең формасы:** катнаш

**Дәрестә укучылар эшчәнлеге:** парлы, индивидуаль.

**Җиһазлар:** басу культураларының һәм кыргый үсемлекләрнең гербарийлары, тестлар, презентация, дидактик биремнәр, басу культуралары орлыкларының коллекциясе, дәреслек В.В.Пасечник.Биология.7 сыйныф, 2016 ел.

**Дәрес барышы:**

**I.Оештыру-мотивлаштыру этабы.**

Исәнмесез укучылар!.Укучылар, игътибарыгызны тәрәзәләргә юнәлтегез әле! Сез нәрсәләр күрәсез? ( укучылар саныйлар : агачлар, чәчәкле үсемлекләр, басу культуралары ).Әйе, укучылар безнең табигатебез үсемлекләргә бик бай икән.

**II.Белемнәрне актуальләштерү.**

1.Үсемлекләрне семьялыкларга бүлегез. **( 1 нче слайд )**

А.Розачалар семьялыгы.

Б.Әвернә чәчәклеләр семьялыгы.

В.Пасленчалар семьялыгы.

Г.Оешма чәчәклеләр семьялыгы.

Д.Күбәләк чәчәклеләр ( кузаклылар ) семьялыгы.

Е.Лаләчәләр семьялыгы.

| | |
|---|---|
| 1.гөлҗимеш | 10.энҗе чәчәк |
| 2.көнбагыш | 11.соя |
| 3.фасоль | 12.тузганак |
| 4.торма | 13.тиле ут |
| 5.борчак | 14.азык шалканы ( турнепс ) |
| 6.томат | 15.шомырт |
| 7.кура җиләге | 16.петуния |
| 8.андыз | 17.гиацинт |
| 9.шалкан | 18.йөзьяшәр ( алоэ ) |

**Җаваплар: ( 2 нче слайд )**

А.Розачалар семьялыгы – 1, 7, 15

Б.Әвернә чәчәклеләр семьялыгы – 4, 9, 14

В.Пасленчалар семьялыгы – 6, 13, 16

Г.Оешма чәчәклеләр семьялыгы – 2, 8, 12

Д.Күбәләк чәчәклеләр ( кузаклылар ) семьялыгы – 3, 5, 11

Е.Лаләчәләр семьялыгы – 10, 17, 18

**Белемнәрне бәяләү өчен критерийлар:**

18 балл – “5” ле

13 - 17 балл – “4” ле

8 – 12 балл - “3” ле

1 – 7 балл - “2” ле

**Үзбәя.**

2.Укучылар мин сезгә кроссворд чишәргә тәкъдим итәм. Кроссвордтагы барлык сорауларга җавап биргән очракта, вертикаль баганада бер сүз чыгачак.**( 3 нче слайд )**

Укучылар кроссвордны парлап чишәләр.

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | | | | | |
| | 2 | | | | | | |
| 3 | | | | | | | |
| | 4 | | | | | | |
| 5 | | | | | | | |
| | | 6 | | | | | |
| | | 7 | | | | | |

1.Сабакның юанаюына китерүче ясалгы тукыма.

2.Микроскопның бер өлеше.

3.Саз акканатының чәчәк төркеме.

4.Лаләчәләр семьялыгына керүче үсемлек.

5.Органик ашламаның бер төре.

6.Шырпы ясаганда кулланыла торган агач.

7.Җимешләре су белән тарала торган үсемлек.

**Җаваплар:** 1.Камбий. 2.Тубус. 3.Чәкән. 4.Суган. 5.Торф. 6.Усак. 7.Зирек.( **4 нче слайд )**

**Укытучы:** Укучылар, барлык сорауларга да җавап таптыгыз.Нинди сүз килеп чыкты?

Укучылар “кукуруз” сүзен әйтәләр.

**Укытучы:** Укучылар, сез ничек уйлыйсыз? Барыбызга да таныш үсемлек – кукуруз кайсы семьялыкка керә? ( укытучы укучыларга киптерелгән кукуруз үсемлеген күрсәтә, укучылар үз фикерләрен әйтәләр). Димәк, без бүген кыяклылар семьялыгы турында сөйләшәчәкбез.

**III.Яңа белемнәр формалаштыру.**

Тема ачыкланганнан соң, укучылар лаборатор эш башкаралар.

**Лаборатор эш. ( 5 нче слайд )**

**Тема:** Кыяклыларның гомуми билгеләре.

**Максат:** Бодай һәм кукуруз мисалында кыяклылар семьялыгының гомуми билгеләрен, биологик үзенчәлекләрен өйрәнү.

**Җиһазлар:** көз көне тамыры белән казып алынган бодай, кукуруз үсемлекләре, лупалар,скальпель, пинцет, кечкенә тарелка, препарат энәсе.

**Эш барышы:**

1.Бодайның һәм кукурузның тамырын, сабагын, яфракларын, җимешләрен җентекләп карагыз.

2.Бодай һәм кукуруздагы охшашлык, аермалык билгеләрен табыгыз.

3.Дәреслектән һәм киптерелгән үсемлекләрне ( бодай, кукуруз ) файдаланып түбәндәге таблицаны тутырыгыз.

| № п/п | Гомуми билгеләре | Бодай | Кукуруз |
|---|---|---|---|
| 1. | Тамыр системасы | чук тамыр | чук тамыр |
| 2. | Сабагы | салам, буынтыклы | тукымалы, буынтыклы |
| 3. | Яфракларының сеңерчәләнүе | параллель | параллель |
| 4. | Җимеш тибы | бөртекчә | бөртекчә |
| 5. | Яфрак җиңсәсе | бар | бар |
| 6. | Чәчәк төркеме | катлаулы башак | себеркәч (серкәчле чәчәк);<br>чәкән ( җимешлекле чәчәк ) |





**Нәтиҗә: ( 6 нчы слайд )**

1.Бер өлешлеләрнең тамыр системасы ике өлешлеләрнең тамыр системасыннан ничек аерыла? ( бер өлешлеләрдә – **чук тамыр**, ә ике өлешлеләрдә - **үзәк тамыр** )


2.Кыяклыларның җимешен ничек атыйлар? ( **бөртекчә** )

3.Кыяклыларда нинди чәчәк төркемнәре була? (**катлаулы башак** – бодай, арпа, арыш, сарут; **себеркәч** – тары, солы; **чәкән** – кукуруз; **тәлгәш ( солтан )** – болын арышбашы)

4.Кыяклыларның яфрак сеңерчәләнүе нинди? ( **параллель** )

5.Нәрсә ул җиңсә? ( **яфракның көпшә рәвешендәге нигезе** )

**IV.Белемнәрне ныгыту. ( 7 нче слайд )**




**Укытучы проблемалы сорау куя:** Укучылар, сез экранда кыяклылар семьялыгына кергән үсемлекләрне күрәсез.Хәзер түбәндәге сорауларга җавап бирегез:

1.Барлык кыяклылар өчен нәрсә хас? Аларны нәрсә берләштерә?

2.Кыяклы үсемлекләрнең тамыр, сабак, яфраклары нинди үзенчәлекләргә ия?

3.Кыяклыларның чәчәкләре нинди чәчәк төркеме тибына җыелган?

4.Кыяклылар семьялыгындагы үсемлекләрнең чәчәкләренә нинди гомуми билгеләр хас? (Укучыларның фикерләре тыңлана )

**Укытучы:** Укучылар, хәзер сезнең белән Актаныш районы басуларында игелүче кыяклы үсемлекләр белән танышып үтәбез. **( 8 нче слайд )**

| №п/п | Культура | Сорты | Мәйданы, га | Уңыш, ц / га |
|---|---|---|---|---|
| 1. | **Көзге арыш** | Подарок | 1835 | 37,70 |
| | | Радонь | 305 | 33,80 |
| | | Тантана | 2035 | 36,50 |
| 2. | **Көзге бодай** | Скипетр | 1406 | 26,80 |
| | | Надежда | 1228 | 27 |
| | | Казанская- 560 | 1628 | 29,50 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | **Язгы бодай** | Ульяновская- 105 | 52 | 26,70 |
| | | Уралосибирская | 856 | 40,60 |
| | | Хаят | 985 | 27 |
| | | Экада -70 | 161 | 26 |
| | | Экада - 109 | 3338 | 29,20 |
| | | Тобольская - 195 | 949 | 39,60 |
| 4. | **Язгы солы** | Аллюр | 80000 | 17 |
| | | Всадник | 206000 | 30,90 |
| | | Дерби | 250000 | 27,80 |
| | | Кентер | 60000 | 40,70 |
| | | Конкур | 100000 | 26,70 |
| | | Рысак | 220000 | 25,80 |
| | | Першерон | 400000 | 20 |
| 5. | **Кукуруз** | Татарский - 6 | 4666 | 304 |

**V.Белемнәрне бәяләү.**

Тест биремнәре. **( 9 нчы слайд )**

1.Татарстан Республикасының һәм Россиянең “Кызыл китабы” на кертелгән кыяклы үсемлек:

а) айравык б) Залесский кылганы в) кылчыксыз кындырак

2.Болын арышбашының чәчәк төркеме:

а) катлаулы башак б) себеркәч в) тәлгәш ( солтан )

3.Кылганның җимеш тибы:

а) бөртекчә б) орлыкча в) кузакча

4.Бер өйле үсемлек:

а) тал б) кукуруз в) киндер

5.Манный ярмасын әзерлиләр:

а) солыдан б) бодайдан в) дөгедән

6.Сабан бодаен чәчәләр:

а) язын б) көзен в) җәен

7. Кайчак 100 елга бер тапкыр чәчәк атучы кыяклы үсемлек:

а) сүсән б) бамбук в) шикәр камышы

8.Шикәр камышының сабагы:

а) салам б) тукымалы в) сусыл сабак

9.Далада үсүче кыяклы үсемлек:

а) кылган б) йонча в) улак солыча ( типчак )

10.Кыяклылар семьялыгына керми торган үсемлек:

а) әспе б) дөге в) акмыек ( бүтәкә үләне )

**Җаваплар:** 1 б, 2 в, 3 б , 4 б , 5 б, 6 а , 7 б, 8 б, 9 в , 10 а. **( 10 нчы слайд )**
**VI.Рефлексия.**

1.Бу тема буенча мин нинди яңалык белдем?

2.Мин максатыма ирештемме?

3.Бүгенге дәрестә алган белем миңа киләчәктә ярдәм итәрме ?

**VII. Өйгә эш.( 11 нче слайд )**

1.п.29 укырга, сорауларга җавап әзерләргә.

2.Макаронны, токмачны, солы печеньесын кайсы кыяклы үсемлекләрнең бөртекчәсеннән әзерлиләр?

3.Реферат язарга: “Кыяклыларның кеше тормышында әһәмияте”.( irekле )